КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 18 ноябрь г.Казань № 1032

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 6 июль, 561 нче номерлы карары белән расланган Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 6 июль, 561 нче карары белән расланган Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктта «(капиталь ремонтлау)» сүзләреннән соң «, Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында авария хәлендә дип билгеләнгән тәртиптә танылган һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы йортларда яшәүчеләрне вакытлыча урнаштыру өчен торак урыннарны арендалау» сүзләрен өстәргә;

7 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле «з» пунктчасы өстәргә:

«з) Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында авария хәлендә дип билгеләнгән тәртиптә танылган һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы йортларда яшәүчеләрне вакытлыча урнаштыру өчен торак урыннарын арендалауга карата – Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында авария хәлендә дип билгеләнгән тәртиптә танылган һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы йортларда яшәүчеләрне вакытлыча урнаштыру өчен арендаланган һәм түләнгән торак урыннар саны»;

9 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле «ж» пунктчасы өстәргә:

«ж) Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында авария хәлендә дип билгеләнгән тәртиптә танылган һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы йортларда яшәүчеләрне вакытлыча урнаштыру өчен торак урыннарны арендалауга карата түбәндәге формула кулланыла:

$$P_i = \sum K \times N \times M,$$

монда:

K – Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында авария хәлендә дип билгеләнгән тәртиптә танылган һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы йортларда яшәүчеләрне вакытлыча урнаштыру өчен торак урынны арендалауның тиешле муниципаль берәмлектә уртача базар бәясе буларак билгеләнә торган 1 айга 1 квадрат метры өчен бәясе;

N – Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында авария хәлендә дип билгеләнгән тәртиптә танылган һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы йортларда яшәүчеләрне вакытлыча урнаштыру өчен торак урын мәйданы;

M – Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында авария хәлендә дип билгеләнгән тәртиптә танылган һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы йортларда яшәүчеләрне вакытлыча урнаштыру өчен торак урынны арендалау айлары саны.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин